Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Суркино авылы Башкарма комитеты

КАРАР

08 апрель 2026 ел № 3

Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл Башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Иске Суркино авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авылы Башкарма комитетының карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- 2015 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында»;

- 2020 елның 14 маендагы 2 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы авыл башкарма комитетының 2015 елның 20 ноябрендәге 17 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү Кагыйдәләре хакында» карарга үзгәрешләр кертү турында»;

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Иске Суркино авылы Үзәк урам, 77 нче йорт; Яңа Суркино авылы, Үзәк урам, 12а территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Суркино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Е.В. Якушкин